**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы № 126 «03»сентябрь, 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2011 елның 1 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш һәм өстәмә кертү хакында (10.10.2018 №115 карар редакциясендә)

«Электр энергетикасы турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2024 елның 13 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 3.1 пунктының тугызынчы абзацына «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы статусы бирелгән затка «Электр энергетикасы турында»гы 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасы статусы бирелгән затка» сүзләрен өстәп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2011 елның 1 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (10.10.2018 №115 карар редакциясендә)
түбәндәге үзгәреш кертергә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина